**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы,423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

КАРАР

2022 елның «04» апреленнән № 112

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының спорт мәктәбе» муниципаль бюджет учреждениесе эшчәнлегенә түләүле һәм башка керем китерә торган хезмәтләр күрсәтү турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2021 елның 31 августындагы 356 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының спорт мәктәбе» муниципаль бюджет учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган түләүле хезмәтләр исемлегенә үзгәрешләр кертү турында

«Коммерцияле булмаган оешмалар турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәнең гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Дәүләт (муниципаль) учреждениеләрнең хокукый хәлен камилләштерүгә бәйле рәвештә Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2010 елның 8 маендагы 83-ФЗ номерлы Федераль Закон, «Кулланучылар хокукларын яклау турында» 1992 елның 7 февралендәге 2300-1 номерлы Россия Федерациясе Законы нигезендә Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының спорт мәктәбе» муниципаль бюджет учреждениесе эшчәнлегенә түләүле һәм башка керем китерә торган хезмәтләр күрсәтү турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2021 елның 31 августындагы 356 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының спорт мәктәбе» муниципаль бюджет учреждениесе тарафыннан физик һәм юридик затларга

күрсәтелә торган түләүле хезмәтләр исемлегенең «Түләүле хезмәтләрнең якынча исемлеге Россия Федерациясе дәүләт стандартының 1993 елның 28 июнендәге 163 номерлы карары белән расланган халыкка хезмәт күрсәтүнең гомумроссия классификаторы нигезендә билгеләнгән» дигән эчтәлектәге 1 абзацын төшереп калдырырга.

Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче Р.Р. Фасахов